| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01.04.2019 г. Заинск № 373

**Зәй муниципаль район Советының 2007 елның 26 июнендәге 130 номерлы «Зәй муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 нче декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнары, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль район Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль район Советының 2007 елның 26 июнендәге 130 номерлы карары (Зәй муниципаль районы Советының 2017 елның 12 октябрендәге 236 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.2 пунктта "Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – район Башкарма комитеты) тарафыннан карар рәвешендә" сүзләрен "Зәй муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан күрсәтмә рәвешендә" сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 6.3 пунктта «муниципаль район Башкарма комитеты карары белән» сүзләрен «Зәй муниципаль районының Мөлкәт һәм жир мөнәсәбәтләре палатасы күрсәтмәсе белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Зәй муниципаль район Советы оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет-финанс мәсьәләләре, икътисадый үсеш һәм муниципаль милек буенча Зәй муниципаль район Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет рәисе** **Р.Г.Кәримов**